ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Балыклы-Чукаевского **СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422655, с.Балыклы-Чукаево,
ул. Центральная, дом 9

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
Балыклы-Чүкәй **АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ**
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422655, Балыклы-Чүкәй авылы
Үзәк урам, 9нчы йорт,

Тел.: (84361) 26357, факс: (84361) 26357, e-mail:blc,rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

17.03.2020 | Балыклы-Чүкәй авылы | № 2

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2004 елның 24 мартындагы “Җирле референдум турында” 23-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, узган гражданнар җыенында кабул ителгән Керәшен Казысы авылы 29.10.2019 г. г. № 15, Балыклы-Чүкәй авылы 30.10.2019 г № 17, Иске Арыш авылы 31.10.2019 г № 19 номерлы карарын тормышка ашыру максатында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыюның кушымта итеп бирелә торган Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авылы, Үзәк урамы, 8 йорт; Иске Арыш авылы, Үзәк урамы, 23в йорт;Керәшен Казысы авылы, Титов урамы, 11б һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Башкарма комитетының баш бухгалтеры Шакирова Фәузия Габделхаковнага йөкләргә.

Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы-Чүкәй авыл жирлеге

башлыгы вазыйфасын башкаручы И.С.Мазитов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2020 елның
17.03дагы
№ 2 номерлы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы**
**“ Балыклы-Чүк авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю**
**Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “ Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “ Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан (белем алуның көндезге формасында укучы студентлардан гайре, аларның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артык була алмый) җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә
2020 елның 31 мартына кадәр башкарыла.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә бланкы (әлеге Тәртипкә кушымта) гражданнар игътибарына Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда игълан итү һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру (халыкка белдерү) ысулы белән, шулай ук кул куйдырып тапшыру юлы белән яисә почта аша юллап җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, тулы яисә киметелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең лицевой счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләүләр акча средстволарын физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган, почта переводларын (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы аркылы яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша ку
юлы белән башкарыла.

6. Түләү фактын раслаучы булып керем (приход) касса ордеры
тамганамәсе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Гражданнарның билгеләнгән срокта кертелмәгән үзара салым акча
законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль р
"Балыклы-Чүкәй авыл жи
муниципаль берәмлеге территори
гражданнарның үзара салым акча
жыю Тәртибенә КУШ

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы " Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча
бер тапкыр түләнелә торган түләүне түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ №_________

Түләүченең Ф.И.А.и.
______________________________________________
Адрес: ______________________________________
______________________________________нигезен
Сезгә 2020 елның 31 мартына кадәр________________
________________________чараларын тормышка ашыруга бер тап
түләнелә торган ________сумма күләмендәге түләүне түбәндәге реквизитлар буе
түләргә кирәк: ______________________________
БИК (банкның таныклаучы коды) алучы банк
________________________________
Сч. № ___________________________
Сч. № алучы______________________________
ИНН ______________________________
КПП ______________________________
КБК _______________ ОКАТО __________________
Түләүнең билгеләнеше
______________________________________________

Җитәкче __________________ ____________________________
М.У. (имза) (имзаның расшифровкасы)

\- - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү сызыгы** - - - - - - - - - - - - - - -

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “_____________ авыл (шәһәр) җирлеге” муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнелә торган ________________сум күләмендәге түләүне түләү турында ХӘБӘРНАМӘ №_________

Түләүченең Ф.И.А.и. ___________________________________________________________

Адрес:_______________________________________________________________________

Алдым “___” _________________, 20__ ел

_____________________________________

(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта ертып алына торган төпсә тутырыла һәм _______________җирлеге Башкарма комитетында кала.*